ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның гамәлдә булу даирәсе**

1. Әлеге Закон "Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында" 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә төзелә торган бүтән дәүләт органнары (алга таба – дәүләт органнары), Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2. Әлеге Законның гамәлдә булу көче мәгълүматтан файдаланучыларның дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагыла.

2 статья. **Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү рәвеше**

1. Дәүләт органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат телдән һәм документлаштырылган мәгълүмат рәвешендә, шул исәптән электрон документ рәвешендә бирелергә мөмкин.

2. Дәүләт органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат, әгәр аларның эшчәнлеге турында мәгълүмат бирүнең бүтән ысулы гаризада күрсәтелмәгән булса, мәгълүматтан файдаланучының язма гаризасына җавап итеп, язма рәвештә бирелә.

3. Дәүләт органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүмат, әгәр ул соралган рәвешендә бирелә алмаса, мәгълүматның нинди рәвештә булуыннан чыгып бирелә. Мәгълүматтан файдаланучыга мәгълүматны соралган рәвешендә бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителергә тиеш, хәбәрдә мәгълүматның мәгълүматтан

файдаланучы тарафыннан күрсәтелгән рәвештә бирелә алмавының сәбәбе күрсәтелергә тиеш.

4. Мәгълүматтан файдаланучыларга дәүләт органнары эшчәнлеге турында телдән мәгълүмат аларны кабул итү вакытында бирелә. Әлеге мәгълүмат шулай ук дәүләт органының белешмә бирү хезмәтләре телефоннары аша йә дәүләт органының мәгълүмат бирергә вәкаләтле вазыйфаи затлары телефоннары аша бирелә.

5. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү рәвеше федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында билгеләнә, шулай ук муниципаль хокукый актларда билгеләнергә мөмкин.

6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат гомуми файдаланудагы элемтә челтәрләре аша тапшырылырга мөмкин.

3 статья. **Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат биргәндә дәүләт телләрен куллану**

1. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирелә.

2. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат соралган гаризаны язганда һәм гаризага җавап биргәндә Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

4 статья. **Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру**

1. Дәүләт органы, җирле үзидарә органы эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге дәүләт органының, җирле үзидарә органының тиешле структур бүлекчәсе яисә вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан тәэмин ителә.

2. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру, Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә гомуми файдаланудагы мәгълүмат системаларына, шул исәптән "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә, шулай ук күрсәтелгән органнар урнашкан биналарда һәм шушы максатлар өчен бүлеп бирелгән урыннарда урнаштырыла.

4. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында китапханә һәм архив фондларында саклана торган мәгълүмат белән мәгълүматтан файдаланучыларны таныштыру китапханә һәм архив эше турындагы Россия Федерациясе законнарында һәм алар нигезендә кабул ителгән бүтән норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә, шулай ук китапханә һәм архив эше турындагы Татарстан Республикасы законнарында һәм дәүләт органнарының,

җирле үзидарә органнарының алар нигезендә кабул ителгән бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5 статья. **Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә урнаштырыла торган мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру**

1. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары үз эшчәнлекләре турында мәгълүмат урнаштыру өчен "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланалар, анда, гариза юллана алган электрон почта адресын күрсәтеп, үзләренең рәсми сайтларын булдыралар. Җирле үзидарә органының үз эшчәнлеге турында мәгълүматны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, күрсәтелгән мәгълүмат Татарстан Республикасының рәсми сайтына (порталына) урнаштырылырга мөмкин. Муниципаль районга керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат шул муниципаль районның рәсми сайтына урнаштырылырга мөмкин.

2. Дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларына мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

3. Дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына карата таләпләр күрсәтелгән органнар тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә билгеләнә.

6 статья. **Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә урнаштырыла торган мәгълүмат исемлекләре**

1. "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан урнаштырыла торган һәркем файдалана алырлык мәгълүматның, шул исәптән ачык белешмәләр рәвешендә урнаштырыла торган мәгълүматның составы (Федераль законның 14 статьясындагы $7^1$ өлешендә күрсәтелгән мәгълүматтан тыш) шул органнар эшчәнлеге турындагы мәгълүматның тиешле исемлекләре белән билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә раслана.

3. Татарстан Республикасы Президенты эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеге Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

5. Бүтән дәүләт органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлекләре шул дәүләт органнары тарафыннан раслана.

6. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә раслана.

7 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 16 гыйнвары
№ 3-ТРЗ